Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Югары Акташ авыл Советы

КАРАРЫ

19 апрель 2022 ел № 44

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль
районы Югары Акташ авыл Советының кайбер
карарларын гамәлдән чыгару турында

Хокукый мониторинг нәтиҗәләре буенча

Югары Акташ авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының түбәндәге карарларын гамәлдән чыгарырга:

2008 елның 23 декабрендәге 80 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында» гы карары;

2009 елның 14 июлендәге 92 номерлы "Әлмәт муниципаль районы" муниципаль берәмлегенә вәкаләтләрне тапшыру турында»гы карары;

2009 елның 25 ноябрендәге 100 номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеге вәкаләтләренең бер өлешен тапшыру турында»гы карары;

2015 елның 27 февралендәге 120 номерлы "Әлмәт муниципаль районының җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карары;

2015 елның 05 маендагы 128 номерлы "Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлегенең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру турында»гы карары ;

2008 елның 24 ноябрендәге 76 номерлы "Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл җирлеген агымдагы ремонтлауга һәм карап тотуга тарифлар турында»гы карары;

2009 елның 25 ноябрендәге 101 номерлы "Коммуналь хезмәтләрне куллану нормативлары турында»гы карары;

2010 елның 24 мартындагы 110 номерлы "Муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Югары Акташ авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмәне раслау хакында»гы карары;

2010 елның 02 сентябрендәге 119 номерлы “Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Югары Акташ авыл Советының 2010 елның 24 мартындагы 110 номерлы «Югары Акташ авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү хакындагы нигезләмәне раслау хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында” гы карары;

2. Әлеге карарны Югары Акташ авылы, Совет урамы, 15 нче йорт торак пункт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Югары Акташ авыл
җирлеге башлыгы А.В.Шатунов